*МАУК «Чишминская районная межпоселенческая библиотека»*
*Информационно-библиографический отдел*

**“Духовная составляющая, языки, традиции
и фольклор народов, заселяющих сёла,
расположенные вдоль реки Кизяк,
в контексте исторической филологии и культуры»**

# Кизәк буе такмаклары



**Чишмы - 2021**



УДК 9.908

**Р.В. Газизова (*Богданова*)**

*п. Чишмы, Башкортостан*

## Миңкәй әби такмаклары

Кизәк буе Кызылгы авылында гомер иткән Миңкәй әбине белмәгән кеше юк. Ә менә аның такмаклар әйтеп, шигырьләр язганын бөтен авылдашлары да белде микән? Белмәгән булсагыз, белегез, дигәндәй, сүз башлыйбыз.

Бәширова Миңкәй Гиниятулла кызы 1905 елда Чишмә районы Бәрсуанбаш авылының крестьян гаиләсендә дөньяга килгән. 1935 елда Миңкәй Кызылгы егете Бәширов Минигази Хисаметдин улына тормышка чыга. Сугышка тиклем ире белән бик тату яшиләр, Мингази абый колхоз рәисе булып эшли, тырыш Миңкәй апа аның уң кулы булып тора. 1941 елда Миңкәй апа ирен сугышка озата, улы Зәет һәм кызы Фәүзия белән кала. Төпчек кызлары Флүзә әнисенең карынында була. Аңа этисенең җылы кулларында уйнарга Ходай насыйп итмәгән: Мингази Бәширов 1943 елның нояберендә хәбәрсез югала.

Күпне күргән, күпне кичергән Баширова Миңкәй тормыш авырлыгына бирешми,тол хатын исеменә тап төшерми балаларына яхшы тәрбия бирә. Кайсы вакытта усал да булырга туры килгәндер, җан әрнүләрен басыр өчен шаяра да белә Миңкәй апа. Бәширова Миңкәй такмаклар, бәетләр чыгарырга оста булган, матур-матур шигырьләр язып калдырган. Шул шигырьләре аркасында җавапка да тарттырылган булган хатын кеше. Ә ул такмакның тарихы болай була.

Ыштаным да чобарлы,

Күлмәгем дә чобарлы,

Сәнәске тартып йөрүне

Сталин уйлап чыгарды,-

дип такмаклый ул, ат урынына җигелеп, авыр чаналар тартып йөк ташыган көннәрнең берсендә. Әлбәттә, бу сүзләр “тиешле” урынга җиткерелә.

Хатынны район үзәгенә тикшеррегә алып китәләр. Комендантның: “Йә, сөйлә, нинди такмак чыгардың син анда? – дигән соравына Миңкәй болай дип җавап кайтара:

“Ыштаның да чоп-чобар,

Күлмәгең дә чоп-чобар.

Балагыңны  бик күтәрмә,

Чыпчыгың чыгып очар, -

дип такмаклаган идем, шул сүземне бригадир ошатмагандыр”, - дип җавап кайтара. Бу такмакка “бәйләнергә” сәбәп тапмый өстә утыручылар, шулай итеп, Миңкәй әби җавапка тартылудан азат була.

Сугышка тиклем Миңкәй әбинең тормыш иптәше Мингази колхоз председателе булып эшли. Ире сугышка алынгач, председатель итеп Закир исемле кешене куялар.  Кичәге председатель хатыны бүген инде кул белән җир сөрергә чыга.

Югары очтан икәү килә,

Кигән кара эшләпә.

Закир казый, Миңкәй сөрә,

Менә донья нишләтә.

Миңкәй апа сугышта югалган ирен  гомере буена сагынып яши.Тол хатын язмышының  ачысын да төчесен дә татырга туры килгән,  җор телле кыю хатын такмакларында күпме мәгънә, күпме кичереш, сагыш һәм әрнү.

Агыйдел белән диңгез

Агуларыбертигез,

Сезнекүрсә, мине сорар,

Бик сагынган диегез.

Ятсам да йоклый алмыймын,

Сандугачларуята,

Сайраган булып юата

Бәхетең юк дип елата.

Эшләсәм эшләмәсәм дә,

Җиннәремне сызганам,

Әрнеп үтә гомерләрем,

Үз үземне кызганам.

Кычкырып бер җырлыйм эле

Моңлы тавышым белән.

Син дә миңа кушылырсың

Кайгы сагышын белән.

Биек тауның башларында
Әллә каргалар микән.
Әрнеп гомере үтсен диеп,
Кемнәр каргады икән.
Сөенәм мин кайчак иртәләрен,
Шөкер кылам язмышка,
Ә кичләрен янә утлар сүнгәч,
Төшәмен шул кайгы-сагышка.
Әйдә, дустым, барасыңмы,
Мин барам бөрлегәнгә.
Кычкырып җырлап җибәрәм,
Йөрәгем әрнегәндә.

Агыйделнең суы тирән,
Атым төшеп эчерәм.
Көн дэ озын, төн дэ озын,
Әрнеп гомер кичерәм.
Безнең мәчетнең ишеге
Кыйбылага  кап-каршы,
Әллә әдәмнәр каргышы,
Әллә ходай язмышы.

Кызылгы бик матур авыл,
Кара урман эчендә.
Беркем белми хәлләремне,
Утлар яна эчемдә.

Миңкәй әби өч баласын: улы Зәет, кызлары Фәүзия белән Флүзәне үстерә. Улы Зәет олыгаеп вафат булгач, Кызылгыдагы кызы Флүзә белән Иске Мусада яшәгән кызы Фәүзия олы яшьтәге әниләрен чиратлашып карый.

Яфраклар җилгә оча
Очып барган кош  кебек.
Мусада торган чагым
Йокыдагы төш кебек.
Уфаларга барыр идем,
Җияү барсам арырмын,
Монда бик куп тордым инде,
Хәзер  кая барырмын.
Тимер белән киртәлиләр

Виноградның бакчасын,
Кемдә торам, шуңа бирәм
Пенсиянең акчасын.

Чулт-чулт итеп кошлар сайрый
Кызылгы якларында.
Тагын килеп кердем инде
Шифоньер артларына.

Иске Мусага китеп торган чакларында гомер иткән йортын, ире белән корган нигезен сагынып яши Миңкәй әби. Кызылгыга һәм авылдашларына багышланган шигырьләре дә байтак аның. Кызылгыда бер холыксызрак ир яшәгән, хатынын да “каты кулда” тота дигән сүз дә йөрегән  аның турында. Ә

инде туры сүзле, төртмә телле Миңкәй әби беркемнән дә куркып тормый. Шундый холыксыз ирләр дә аның такмалары тарихына кереп калган.

Уфаларга барыр өчен
Атның җиктем кашкасын.
Кызылгыларны сагындым
Шахинурдан башкасын.

Миңнекәй апа Башировага Ходай шатлык-көенечләргә тулы озын гомер язган. Ул 103 яшькә тиклем гомер итә. Соңгы көннәргә кадәр уз аңында, саф уй-фикерле була. Адәм баласы шундый инде ул: теге дөньяга күчү турында уйлар, олыгайган саен, башка ешрак керә. Миңкәй әбине дә андый уйланулар урап үтмәгән. Шул уйлар шигъри юлларга яткан.

Алтын йөзекләр койдырдым,
Үлчәп карап зурлыгын.
Кабрем өстенә чәчегез
Бу чәчәкнен орлыгын.
Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мөслимә.
Тасбих әйтеп утырырлар
Каберемнең өстендә.

Сандугачның балалары
Кайсы берсе каралар,
Бер мин генә түгел инде,
Бар да шунда баралар.
Алмагачтан алма җыйдым,
Аны ничек бүләргә?
Бер дә үләсе килми дә бит,
Вакыт җитте үләргә.

Нинди генә булмасын тормыш: авырмы-җиңелме, озынмы-кыскамы, парлымы-ялгызмы, беркем дә бу дөньядан тумый, гомер бик тиз үткән кебек. Кеше гомере – аккан су, дип юкка әйтмиләрдер. Ул шулкадәр кыска ки, әйләнеп карарга һәм нәрсәдер аңларга да өлгерә алмыйсың, утларында яндырып, сагыш-моңга салып уза да китә гомер дигән кадерле мизгел. Бу сүзләрне Миңкәй апаның шигырьләре исбат итеп тора.

Җир җиләген бик күп
җыйдым,
Савытларым тулмады,

Туксан ел гомер кичердем,
Тугызай да булмады.
Исем китеп карап торам

Җилсезтузан тузганын.
Үзем сизми дә калдым мин
Гомеремнең узганын.

Укымышлы хатын тирә-якта булган вакыйгалар турында хәбәрләр белән кызыксынып тора. Кайсы берсенә багышлап бәетләр дә яза ул. Киләсе бәет нәкъ менә Иске Мусадан ерак булмаган Ибраһим авылында булган фаҗигале вакыйгага багышланган.

Уразаны тоттым да бит
Күрә алмадым гаетен,
Сез тыңлагыз, мин әйтәмен
Сәҗидәләр бәетен.
Ибраһим урманында
Бик куп икән юкә агач.
Ибраһимда бер  хәл булган,
Бөтен халык йоклагач.
Алар алма жыйганнар да,
Аны икәүбүлгәннәр.
Хамит белән Сәҗидә
Утта янып үлгәннәр.<…>
Сандугачлар моңлы сайрый
Сызылып таңнар атканда.
Беркая бара алмадык
Тәнебезгә ут капканда.
Тәрәзәнең төпләрендә
Чәчәк аткан гөл генә,
Балаларым кайтуына
Калды кара көл генә.<…>

Тазалык – зур байлык, ә йөзгә җиткән карчыктан да күбрәк бу турыда кем уйлана микән?

Бакчаларда алмагач,
Кистем алма булмагач,
Төн чыгулары бик авыр,
Тазалыгың булмагач.
Аргы яктан бирге якка,
Чыгып килә кесәмче
Озын гомерләр биргәнче,
Исәнлегем бирсәңче.

Сүз азагында шуны әйтәсе килә, Миңкәй әбинең бик күп санлы такмаклары, бәетләре аның кызы һәм авылдашлары белән кадерләп язып алынган, алар авыл һәм район китапханәсендә саклана. Бу шигъри юлларда авылның тарихы яши, ул тарих киләсе буыннарга да җиткерелер.

## Хәлим бабай такмаклары

Кизәк буендагы Абрай белән Кызылгыны тоташтырган юл буенда 20 нче гасырның 80 нче елларына тиклем гади булмаган язмышлы бер ир заты яши. Аның



исеме ***Мусалимов Хәлим Сагит*** улы. Хәлим абый язмышының гадәттән тыш булуы аның яшәү рәвешендә була. Мусалимов Хәлим 1909 елда дүрт балалы гаиләдә туа. Авылдашлары хәтерләве буенча, Хәлим үсмер чагында холыксыз, үзсүзле, тискәре була, әти-әнисен тыңлашмый. Шул сәбәптән ул туган өеннән чыгып китә һәм урман эчендә җир йортта *(землянкада)* яши башлый. Мусалимов Хәлим ул вакытта төзелгән колхозларга керергә теләми, үз көнен үзе күрә: халыкка ялланып утын яра, йорт эшләрен эшли. Ул чабата, аркан үрергә бик оста булган икән. Шуларны азыкка алыштырып тамагын туйдырган, өс-башына кием туплаган.

Абрайлылар һәм кызылгылылар аның җир йортын әле дә хәтерли. Кыю бала-чага Хәлим бабайның ул өенә кереп кунак булып та йөрегән. Анда ир кеше үзенә йокларга, ашарга урыннар ясап куйган булган, йортының диварлары читләвек чыбыгыннан, агачтан һәм балчыктан була. Урман эчендә дәрвишнең (отшельник) яшелчә бакчасы да була, анда ул бәрәңге, кишер кебек яшелчәләр үстерә. Әлеге вакытта бу урын “Хәлим чокыры” дип халык телендә атала.

Советлар Союзы вакытында бу күренеш, әлбәттә, гадәттән тыш күренеш була. Хәтта, илләр арасында салкын сугыш барган чорда, Хәлим Мусалимов турында АКШ ның Би-би-си телерадио компаниясендә сөйләгәннәр, диләр. Бу хәлдән соң аңа "Коммунизм" колхозы өр-яңа өй салып бирә. Ләкин Хәлим анда барыбер яшәми, олыгайганчы дәрвишләрчә яшәвен дәвам итә. Олыгаеп, хәле авырлашкач, Хәлим абыйны Иске Муса дәваханәсенә урнаштыралар. Аны анда соңгы көннәренә кадәр дәваханәнең баш табибы Хайретдинов Наиль тәрбияләп карый.

Авылдашлар хәтерләве буенча Хәлим абый гармунда уйный белгән һәм такмаклар чыгарырга оста булган. Вакытында язылып алынмаган булса да, авылдашлар аны телдән хәтерли. Шуларның бер өлеше язып алынды.

Әй, булмаган, булмаган,
Хәлим кебек тумаган.
Безнең Хәлим бигрәк уңган,
Бар Рәсәйне ураган.

Син дә чибәр, мин дә чибәр,
Көзгегә карап җибәр.
Абрай дигән авылда
Иң чибәре мин диләр.

Әй, булмаган, булмаган,
Хәлим кебек тумаган.
Эшкә дисәң эч авырта,
Ашаганда ударник.

Иртә дә кил, кич тә кил,
Тәрәзәмне чиртә кил.
Чиртүеңнән танырмын да
Каршы чыгып алырмын.

Иртә килермен дидең,
Кич тә килермен дидең.
Алтын йөзек, куш беләзек
Алып бирермен дидең.



